## Гөрләп үтсен Сабан


СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

7 июнь, 1997ел.
ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.

№ 62 (8074)

Бәясе билгеләнгәнчә


## КҮРКӘМ ЭШНЕҢ КҮМӘК БӘЙРӘМЕ

Бүген - халкыбызның иң көтеп ала торган бәйрәмнәреннән берсе - Сабан туе. Авыл халкы кыр эшләренең киеренкелегеннән бер кат бушангач, күп таңнарны кырда аттырып сабанда сайрашып, яңа уңышка ышанычлы нигез салып куеп килә ул бәйрәмгә. Бу яктан районыбыз авыл хезмәтчәннәре Сабан туен изге бурычларын намус белән башкарып чыгуларыннан туган зур горурлык хисе белән каршы алдылар. Игенчеләребез язгы кыр эшләренә республикада иң беренчеләрдән булып керештеләр һәм алынган темпны ахыргача саклап мөһим кампанияне уңышлы тәгәлләделәр. Быелгы язга хуҗалык итүнең яңа формаларын куллануга күчеп, яңа хезмәт берләшмәләре - кооперативларга тупланып чыккан игенчеләребез уңыш язмышы өчен көрәштә чын - чынлап фидакарьрлек үрнәкләре күрсәттеләр, бу киеренке чорда көнне - төнгә ялгап эшләделәр. Зур оешканлыкның нәтиҗәсе күз алдында.

Уҗым культуралары башта иртә яздан, аннан соң куакланунң соңгы стадиясендә минераль ашлама белән тукландырылды, шуңа да быел көзге бодай һәм арышның мул уңышына өмет ныклы. Сабан чәчүендә дым саклаулы, чыгымнарны мөмкин кадәр киметүгә юнәлтелгән технологияләргә, югары сыйфатлы һәм кыйммәтле культураларның мәйданнарын арттыруга йөз тотылды. Шул максаттан хуҗалыкларда 128 чәчү агрегаты оештырылды, һәр хуҗалыкта минераль ашлама төягечләр булдырылды, үзебезнең Норлат машина төзү заводында ясалган яңа төр культиваторларны куллану туфракны беренчел эшкәртеп кенә чәчү алымын киң файдаланырга мөмкинлек бирде. Шуңа күрә сабан культуралары туфракта дым күп чакта җиргә күмдерелде. Чәчүлекләрне чүп үләннәрдән һәм корткычлардан саклау препаратларының киң җыелмасын булдырып, аларны куллану эшен бер оешма кулына туплау игенчеләребезгә язгы кыр эшләрен тоткарлыксыз алып барырга мөмкинлек бирде.

Быел язгы бодайның мәйданнары 29 мең гектар чамасы тәшкил итә, бөртек өчен кукуруз 3 мең гектарга якын мәйданда игелә, сенаж максатларына аксымга бай борчак культурасы мәйданнары күпкә арттырылды, сөтне арттыруга зур этәргеч ясый торган азык чөгендере мәйданнары да ишле. Сабан чәчүе мәйданнары елдагыдан ишлерәк булуга да карамастан, бөртекле культураларны, беренче чиратта бодайны аркылыга - буйга һәм эзгә - эз чәчү технологиясе киң кулланылды һәм һәр очракта да рәтләргә минераль ашлама кертелде. Бу үсемлекләрнең тиешле куелыгына ирешергә мөмкинлек бирде. Чәчүлекләрне минераль ашлама белән өстәмә тукландыру уздыру уңышка гарантияне тагын да ныгыта.

Быел алдынгы француз технологиясе буенча игелә торган шикәр чөгендере мәйданнары арттырылды һәм хәзер ул культураның тугыз хуҗалыктагы 1600 гектары кул хезмәте кулланылмыйча үстерелә. Хатын - кызларның хезмәтен җиңеләйтүгә булышлык итүче немец чәчкечләре дә максималь файдаланылды.

Быелгы уңышка ныклы нигез салып куйган игенчеләребез уңыш язмышы өчен көрәштә әле дә киеренкелекне сүрелдермиләр. Бүген басуларда үсемлекләрне саклау чаралары уздырыла, шикәр чөгендере, кукуруз плантацияләрендә дә эш колач җәя. Бер үк вакытта хуҗалыкларда терлек азыгы хәзерләү кебек мөһим кампаниягә чынлап торып тотындылар. Әле ике генә көн элек уздырылган куст семинарларында быел бу эшне башкарып чыгуның үзенчәлекләре турында җентекле сөйләшү булды. Семинарларда малларны җәйге лагерь шартларында асрауга иртә күчерүнең уңай нәтиҗәләре һәм бу чорда терлекчеләр алдында торган бурычлар, терлек каралтыларын кышлату чорына үрнәк төстә әзерләү, беренче чиратта малларны чыгымнарны киметүгә юнәлдерелгән ысуллар белән асрау технолиясен киң кертү мәсьәләләре турында эшлекле сөйләшү алып бардылар. Терлекчеләребезнең бу бәйрәмгә сөт һәм ит реализацияләүнең яртыеллык планнарын вакытыннан күпкә алдан үтәп килүләре турында алдагы санда гына хәбәр иттек. Сөт җитештерүчеләребез бүген дә темпны югары тоталар. Район буенча бер сыердан көнгә уртача 13 килограммнан артыграк сөт савыла, хәзерләүләр пунктларына көн саен 130 тоннадан артыграк продукция озатыла. Бу - узган елның шул чорындагыдан 50 тоннага күбрәк. Сөт муллыгы өчен ярышның иң алгы сафында атлаучы «Кондырча»да бу көннәрдә сыерларның продуктлылыгы 24, Дуслыкта 23,5, Мичурин исемендәге хуҗалыкта 20, «Якты Күл»дә һәм «Агрохимсервис»ның ярдәмче хуҗалыгында 17,1, «Рассвет», «Киекле»дә 15 килограммнан артыграк, тагын дистәләгән хуҗалыкта 13 килограммга якын һәм аннан да артыграк. Ирешелгәннәр әле чик түгел.

Авыл эшчәннәренең, районыбызның барлык хезмәт коллективларының, барлык халкының уртак бәйрәме булган Сабан туе, андагы күңел күтәренкелеге алга таба тагын да зуррак эшләргә, тагын да күркәмрәк нәтиҗәләргә ирешүгә этәргеч булыр дип ышанабыз.

## Сабантуйга - яңа аэропорт



Норлатта Сабан туе гомер - гомергә аэропорт мәйдынында үткәрелеп килгәнгә, бәйге мәйданы белән аэропорт мәйданы норлатлылар аңында бер - берсеннән аерылгысыз. Элегрәк ул бәйләнеш сабантуйга кадәр бер - ике көн алдан, аннан соң төшкә кадәр Норлат - Казан самолетының очуы туктатылып торуга гына кайтып кала торган иде. Аннары әле самолет төшеп утыра торган болынлыкның болай да сезонлы характерда булганлыгы да сер түгел. Шуңа күрә былтыр көз районның яңа җитәкчелеге елның һәм һаваның теләсә нинди вакытында да самолетлар төшеп утыру һәм очып китү мөмкин булсын өчен махсус асфальт полоса салдыруга тотынды. Иңе 28 метр, озынлыгы бер километрдан артык булган ул полоса юл төзелеше өчен гаять катлаулы булган шартларда да билгеләнгән срокка - ноябрь башына өлгерде һәм хәзер инде республикабыз башкаласы Казанга самолет белән сәгатьтән азрак вакыт эчендә барып җитүнең бер кыенлыгы да юк.

Әмма аэропортта эш моның белән генә тәмамланмады. Төзүчеләр алдына гаять зур эш - аэровокзалның заманча бинасын быелгы Сабантуйга өлгертү бурычы куелды.

(Ахыры 2 нче биттә).

### «Уйнагыз гармуннар»да катнаштылар

Май азагында Казанда үткән «Уйнагыз гармуннар» республика бәйрәмендә безнең район вәкилләре дә катнашты.

Алар арасында РСУдан Илсур Мусин, Чулпаннан Фәнил Хәлимов, Аксумладан Ирина Семенова һәм Норлаттан Ирина Сафандеева бар иде.

## Соң булса да, уң булсын

Кадерле дуслар! 5 нче июнь көнне без Бөтендөнья табигатьне саклау көнен билгеләп үттек. Без Татарстан Республикасы экологик фондының Көньяк - Көнчыгыш бүлеге тирә - як мохитны чистарту, табигатьне - чиста һаваны, яшеллекне саклау өчен аз көч куймыйбыз. Шулай да, бу изге эш, киләчәк буынны тәрбияләүдә, аның сәламәтлеген, генофондны саклау буенча әллә нинди фондлар оешса да һәркем аны үз җаваплылыгына алмаса, экология кебек гомуми проблеманы хәл итүгә ирешеп булмаячагы көн кебек ачык. Шуңа да һәркемне бу мәсьәләгә җитдирәк карарга, үзебез яшәгән җирне якын күрергә, үз итәргә чакырабыз. Бердәм көч белән без шактый проблемаларны хәл итә алырбыз, тирә - ягыбызның чисталыгын да саклый алырбыз дип ышанабыз.

Соң булса да табигать кочагында яшәүче һәркемне бәйрәм белән котлыйбыз. Сезгә иминлек, сәламәтлек телибез, сулыйсы һавагыз саф, эчәсе суыгыз чиста, йөрисе юлларыгыз тигез булсын, тирә - як мохитне сәламәтләндерүдә уңышлар юлдаш булсын.

**И.БАКИРОВ.**
**ТР экофондының көньяк - көнчыгыш бүлеге директоры.**

